

13 ноября в детском саду № 30 (заведующая Митрофанова И.Н) прошла спортивно-интеллектуальная игра «По дороге безопасности» с участием семейных команд. Мероприятие было организовано в рамках республиканского декадника, посвященного Всемирному дню памяти жертв дорожных аварий.

Воспитанники детского сада и их родители вместе со сказочным персонажем в исполнении Л. М. Быстровой под руководством ведущего конкурса Г. Я. Пестовой состязались в знании транспортных средств по эмблемам, маневрировали на спортивном этапе, разгадывали ребусы, собирали автомобиль, оказывали медицинскую помощь, накладывая шину на конечность, показывали умение правильного крепления детского удерживающего устройства. Не обошлось и без конкурса капитанов.

По окончании игры призерам были вручены подарки и дипломы: победителем стала семья Салаховых (капитан команды Амина), 2 место разделили семьи Найденых (капитан команды Арина) и семья Хасановых (капитан команды Данис), а "бронза" досталась семье Валиевых (капитан команды Азат).

С 10 по 19 ноября в рамках декадника БДД также пройдут профилактическиеакции «Зебра», «Внимание – пешеход!», «Вежливый водитель», «Автокресло – детям». А в третье воскресенье ноября, во Всемирный день памяти жертв ДТП, во всех российских регионах, в том числе и в Бугульминском районе, состоятся мероприятия, призывающие общественность вспомнить о людях, погибших в автокатастрофах.

Инспектор по пропаганде БДД
ОГИБДД ОМВД России по Бугульминскому району
Ст.л-т полиции Гибадуллина Г.М.

# Бугульминская газета

Издаётся с 1919 года

Пятница 5 февраля 2016 года

№ 8 (14865)

НОВОСТИ




Фото авторов

## КАРНАВАЛ СНЕЖИНОК

Праздник «Зимушка-хрустальная» прошёл в детском саду № 30 «Ёлочка». Используя мультимедийный экран, в доступной и занимательной форме воспитатели рассказали ребятам о прекрасной зимней поре. Дети называли её приметы, читали стихи на русском и татарском языках, прослушали музыкальное произведение «Времена года», любовались из окна зимним пейзажем. Ознакомились и с творчеством татарской поэтессы Гульшат Зайнашевой.

На праздник к ребятам пришла Снегурочка и предложила поучаствовать в конкурсе пословиц и загадок, подарила волшебную снежинку и попросила смастерить такие же для украшения группы. Сколько радости, неподдельного веселья и задора было в глазах ребятишек, которые потом любовались карнавалом своих снежинок.

После образовательной части воспитанники совершили экскурсию в зимний парк и с интересом рассматривали на падающие снежинки с такими разными, замысловатыми узорами.

**Татьяна КУПРИЯНОВА, Венера ЗАРЕЕВА, воспитатели**

## ҖОМГА КИЧЕНДӘ

# "Милли курчаклар" бәйгесе җиңүчеләре



**Шәһәр һәм район мәктәпкәчә тәрбия оешмалары арасында узган бәйгенең җиңүчеләре булып түбәндәге балалар бакчалары танылды.**

**"Зур курчаклар" номинациясендә:** I урында – 14 нче прогимназия; II урында – 18 нче һәм 28 нче балалар бакчалары; III урында – 15 нче балалар бакчасы.

**"Кечкенә курчаклар" номинациясендә:** I урында – 27 нче һәм 38 нче балалар бакчалары; II урында – 8 нче, 12 нче һәм 35 нче балалар бакчалары; III урында – 4 нче, 16 нчы һәм 31 нче балалар бакчалары.

**Авыл балалар бакчалары арасында:**

I урында – Карабаш бистәсе 2 нче балалар бакчасы; II урында – Кодаш авылы балалар бакчасы; III урында – Акбаш һәм Восточный авыллары балалар бакчалары.

Шулай ук махсус номинацияләрдә җиңгән балалар бакчалары да билгеләп үтелде. Менә алар:

**"Иң яхшы милли ательe"** – 19 нчы балалар бакчасында; **"Иң яхшы иҗади табыш"** – 33 нче балалар бакчасында; **"Иң авангард милли костюм"** – 24 нче балалар бакчасында; **"Иң яхшы татар костюмы"** – 6 нчы балалар бакчасында; **"Иң яхшы рус костюмы"** – 39 нчы балалар бакчасында; **"Иң яхшы мари костюмы"** – 37 нче балалар бакчасында; **"Иң яхшы мордва костюмы"** – 30 нчы балалар бакчасында; **"Иң яхшы башкорт костюмы"** – 32 нче балалар бакчасында; **"Иң яхшы удмурт костюмы"** – 20 нче балалар бакчасында.

**Руслан ҖӘЛӘЕВ.**
**Автор фотосы.**

**Рәсемдә:** *бәйгенең "Зур курчаклар" номинациясендә шәһәребезнең 14 нче "Журавушка" прогимназиясе "Дуслык күпере" күргәзмәсе белән җиңү яулады.*

Йомгак

СКАНВОРД

## Великая Отечественная



# Мой дед – герой-победитель

**В гости к дошколятам, в детский сад № 30 «Ёлочка», пришёл ветеран, участник Великой Отечественной войны Максим Иосипович Коваль.**

Тепло и радушно приняли его дети. Неожиданностью для ветерана стала презентация с его фронтовыми фотографиями, которую показали детям. Со слезами на глазах он вспомнил далёкие, тяжёлые боевые дни. А после ребята спели ему и показали задорные танцы. Когда зазвучала «Катюша» в исполнении хора воспитанников, Максим Иосипович подпевал и даже подтанцовывал. В конце праздника дети пообщались с ветераном, рассмотрели его ордена и награды и вручили букет.

**Надежда РОГ,**
**воспитатель**
**Фото автора**

**БҮГЕНГЕ САНДА** Ил-көн сулышы (2 бит). Бәйрәм кайтавазы (5 бит). Ызандашлар (7 бит).

# БӨГЕЛМӘ АВАЗЫ

Җомга
1
декабрь 2017

татмедиа

1991 елның
1 гыйнварыннан чыга
№ 90 (4576)

Иҗтимагый-сәяси, мәдәни газета

lai-ru@yandex.ru / bugulma-tat.ru

## Без – Җир балалары



**2017 ел Экология һәм аерым табигый территорияләрне саклау елы дип игълан ителгән иде. Безнең 30 нчы санлы балалар бакчасында да (мөдиребез – И.Н. Митрофанова) экология төшенчәсен аңлау һәм аңлату, аның чисталыгын саклауның мөһимлеген, бу юнәлештә кулдан килердәй эш алымнарын ачыклау, өйрәнү максатыннан, бакчада эшләүчеләр арасында да, балалар һәм аларның ата-аналары белән дә эш алып барыла: төрле акцияләр, бәйгеләр, чаралар оештырыла.**

Ноябрьнең соңгы атнасында бакчабыздагы эшчәнлек тулысынча экологик тәрбия темасына багышланды. 2 нче урта яшьтәге балалар төркемендә без – тәрбиячеләр: Татьяна Григорьевна Куприянова һәм шушы юлларның авторы – Венера Асым кызы Зареева табигатькә бәйле һөнәрләргә багышланган ачык чара уздырдык.

Балалар фермер һәм урманчы һөнәрләре турында үзләре өчен күп яңалык ачтылар, төрле уеннар аша кыргый һәм йорт хайваннарын танып-белергә өйрәнделәр, туган якта очрый торган кошларны атадылар. Чара ахырында барлык балалар да бер нәтиҗәгә килде: бар кеше өчен дә иң мөһим остаз-укытучы ул – Табигать-Ана һәм аны сакларга кирәк.

Әйе, балаларны кечкенәдән үк тирә-юньнең гүзәллеген күрә белергә өйрәтсәк, алар кешенең табигатьтән аерылгысыз икәнлеген аңласалар, әйләнә-тирә мохиткә, табигатьнең үзенә сак карарга кирәклеген дә төшенерләр, үскәч тә кешеләрнең – әти-әниләренең, дусларының һәм, билгеле, кече туганнар саналган җәнлек-кошларның, ягъни табигать балаларының да кадерен белерләр.

**Венера ЗАРЕЕВА,**
**30 нчы балалар бакчасы тәрбиячесе.**
**/Фото – автордан/.**

Бугульминская газета
Пятница 12 августа 2016 года
№ 59 (14916)

## НЕДЕЛЯ ЦВЕТОВ

В детском саду № 30 «Ёлочка» провели неделю цветов. Дети их собирали, лепили и рисовали, пели песни о цветах, носили одежду в «цветочек». А ещё дошколята решили поддержать российских спортсменов на Олимпиаде – они создали цветочную композицию из пяти колец.

Подготовила Наталья МАРКОВЕЦ

профориентация

# Тропинка к будущему

Творческий отчёт для руководителей дошкольных учреждений на тему «Формирование у воспитанников профориентационных знаний» прошёл в одном из детских садов города, где активно работают по этой программе.

Сначала педагоги показали презентации о различных профессиях. Были представлены архитектор и доярка, стюардесса и охранник, музыкант и повар. Дети стали полноправными участниками импровизированного ток-шоу о выборе своего будущего. В «Мастер-шефе» они выступали в роли лучших поваров страны. В «Школе ремонта» пробовали себя как дизайнеры. А в рамках программы «Модный приговор» почувствовали себя настоящими моделями во время эксклюзивного показа мод «Подиум Д'Арт». Большую помощь оказали родители, проявив творчество в изготовлении оригинальных костюмов из бросового материала.

С заключительными словами на тему: «Какой она будет тропинка твоя?» выступила заведующая детским садом № 30.

В заключение решено было представить опыт бугульминской работы на курсах повышения квалификации педагогов республики.

**Гульнара ПЕСТОВА,**
**воспитатель**



Бәйгенең җиңүчеләре – Бәдриевлар гаиләсе.

**Әти – безнең терәгебез,**
**Әти – безне яклаучы.**
**Авырлыклар китермичә,**
**Давыллардан саклаучы!**

Әлеге сүзләр һәр сабыйның күңеленә кечкенә чактан ук кереп калырга тиеш. Әйе, һәр бала тормышта булган авырлыклардан, давыллардан саклаучы итеп нәкъ менә әтиләрен тоя, алар белән горурлана. Сәхнәгә ярышка чыккан Булат Фәсхетдинов

лар үткәргән, [illegible]

кеше кесәсенә кереп тормаган алып баручы Эдуард Гафиятуллин да, бу кадәр талантлы, үткен әтиләрне, аларга ярдәм иткән хәләл җефетләрен, берсеннән-берсе күркәм балаларны күреп, бермәлгә хәтта телсез дә калып торгалады. Хәер, эшен тиешле югарылыкта башкарып чыкты ул, тамашачыны тәмам җәлеп иткән бәйге бер тында үтте дә китте. Киләсе елларда да үткәрелсен, озын гомерле булсын иде дип телисе генә калды.

Мәртәбәле жюри әгъзалары йомгак ясаган мәлдә дә сәхнә тынып тормады. Бер-бер артлы талант иядәре чыгып, тамашачыга ялыгырга ирек бирмәделәр. Нәтиҗәләр исә түбәндәгечә булды. Бәйгедә катнашып, "Иң милли гаилә" – Мифтаховлар гаиләсе (38 нче балалар бакчасы), "Иң талантлы гаилә" – Гыйззәтуллиннар гаиләсе (14 нче прогимназия), "Иң уңган гаилә" – Мостафиннар гаиләсе (24 нче балалар бакчасы), "Тамашачы мәхәббәтен яулаган гаилә" исеменә Фәсхетдиновлар (23 нче балалар бакчасы) лаек булды. Сәлаховлар гаиләсе (30 нчы балалар бакчасы) – III урында, II урынны Нәфыйковлар гаиләсе (18 нче балалар бакчасы)



Ленар Сәлахов – кок.

яулады. Бәйгенең җиңүчесе дип Бәдриевлар гаиләсе (15 нче балалар бакчасы) танылды. Афәрин, әтиләр! Афәрин, гаиләләр! Бегелмәдә шундый да талантлы, шундый да күркәм гаиләләр булуына ничек сөенмисең ди инде!?

**Руслан ҖӘЛӘЕВ.**
**Автор фотолары.**



Тамашачылар менә шулай көч биреп торды.



Ленар Нәфыйков автомат сүтеп-җыйганда.

## КӨЧЛЕ ЗАТЛАР КӨЧ СЫНАШТЫ

**Фоторепортаж**

**Шәһәребезнең Татар мәдәният үзәгендә күркәм чаралар даими булып тора. Шундыйларның берсе – 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне уңаеннан үткәрелгән "Ягез әле, әтиләр!" бәйгесе. Биредә шуны да искәртергә кирәк, әлеге чара беренче тапкыр үткәрелде һәм үзенең тамашачыларны җәлеп итә алу ягыннан бик тә тәэсирле булды. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки сәхнәгә шәһәребезнең төрле балалар бакчаларында тәрбияләнүче сабыйларның әтиләре чыгып, күп кенә номинацияләрдә көч сынашты, гаиләләре, туганнары, якыннары алар өчен җан атып, җиңүләрен теләп торды, ләбаса.**



*Менә алар – үрнәк әтиләр.*



# ЯГЕЗ ӘЛЕ, ӘТИЛӘР!

(23 нче балалар бакчасы), Ленар Нәфыйков (18 нче), Илдус Мостафин (24 нче), Рәмис Гыйззәтуллин (14 нче прогимназия), Ленар Сәлахов (30 нчы), Айдар Мифтахов (38 нче) һәм Илдар Бәдриев (15 нче балалар бакчасы) белән бу көнне, чыннан да, горурланырлык иде шул. Ник дигәндә, бәйгенең беренче өлешендә – "Таныш булыйк"; икенче номинациядә – автоматны тизлеккә сүтеп-җыюда, көчлелектә сынашу; өченче өлештә – иҗатларын: җыр, бию һәм башка маһирлыкларын күрсәтү һәм ахырдан аш-суга осталыкларын тәкъдир итүләре белән тамашачы һәм жюри әгъзаларын да таң калдырдылар. Мондый бәйгеләрне инде күп тапкыр-



Фестиваль

# ЯЗГЫ ТАМЧЫЛАР

**"Язгы тамчылар" балалар иҗат фестивале шәһәр күләмендә ел да үтә торган матур бер традициягә әйләнде. Балалар бакчаларында тәрбияләнүче нәниләр генә түгел, анда эшләүче педагоглар да читтә калмый бу чарадан.**

**Равидә БИГЛОВА,**
**татар төркеме тәрбиячеләренең методик берләшмә җитәкчесе.**

Быелгы фестиваль Роберт Миңнуллин иҗатына, аның юбилеена багышланган иде. Бу шулай ук балалар күңеленә милли рух орлыкларын салырга омтылу да, аларның талантларын барлау, ачу кебек мөһим бурычны да күз алдында тота торган чараларның берсе булды. Балалар берсеннән-берсе уздырып, бик оста итеп Роберт Миңнуллинның "Елмаючы бүреләр", "Хәрефләр бәйрәме", "Юк инде", "Чикерткә" һәм башка шигырьләрен сәхнәләштергәннәр. 3 нче балалар бакчасыннан Әмир Мөбарәкшинның: "Юкка малай булганмын", – дип "уфтануын" көлмичә тыңлап булмады. Ә инде Карабаш бистәсе 2 нче балалар бакчасыннан килгән Гүзәл Миңнәхмәтова башкаруында "Туган көн" җыры, 32 нче балалар бакчасы балаларының "Кыр казлары" биюе көчле алкышларга лаек булды. Концерт программмасын зур осталык белән "Батыр" бакчасының өлкән тәрбиячесе Гөлшат Борһанова алып барды, ә сәхнәне зәвыклы итеп бизәүдә 24 нче, 37 нче балалар бакчасы катнашты. Әлбәттә, бу фестивальнең шундый җанлы, күңелле итеп узуына Татар мәдәният үзәге директоры Флюра Әхмәтвәли кызы Шәрипова да зур өлеш кертте.

Ә тамашачы булып килгән әбиләр, бабайлар исә: "Милли хисләрдә тәрбияләнгән бала тәүфыйклы була", – дип сөенеп, чарага карата үзләренең фикерләрен җиткерделәр.



"Әгерҗе авазы" июнь 2013 г.

## 2014 ЕЛ – МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ

Семинардан соң уйланулар

# ТУГАН ТЕЛЕМ ТУРЫНДА

**Гыйнвар азагында 30 нчы "Чыршыкай" мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә балалар бакчалары мөдирләре өчен татар телен өйрәтүнең сыйфатын күтәрүгә багышланган семинар-тренинг булып узды.**

Гөлфинә ШАКИРОВА,
30 нчы "Чыршыкай" балалар бакчасы тәрбиячесе.
Л. Шакирҗанова фотосы.



Семинар мәгариф идарәсе методисты Фәридә Кадыйрова чыгышы белән башланып китте, соңрак берсеннән-берсе мавыктыргыч чаралар белән дәвам итте: балаларның җырлы-биюле сәламләүләре, бакча мөдире И. Митрофанованың эш тәҗрибәсеннән чыгып ясаган презентациясе, педагоглар чыгышы, белем бирү эшчәнлеген карау, мастер-класс, эрудит-лото һәм башкалар.

Соңыннан семинар эшенә йомгак ясалды. Үткәрелгән барлык чаралар да югары бәя алды. Бу безнең коллектив өчен зур шатлык булды, алдагы эшчәнлеккә дәрт өстәде. Ә шәхсән минем өчен әлеге чара бер бәйрәм төсендә үтте. Бердән, семинарга хәзерлек чорында бакчабызда татар теле, татар моңы яңгырап торса, икенчедән, рустелле тәрбиячеләр авызыннан шаярып кына да "нигә кирәк безгә татар теле, ник безне юкка интектерәләр" кебек сүзләр ишетергә туры килмәде. Алар, бер-берсе белән ярыша-ярыша, татарча телләрен "чарлады"лар, сүз байлыкларын арттырдылар.

Ә бит, кем әйтмешли, бар иде заманалар. 28 ел элек бакчага эшкә урнашканда минем 3 яшьлек улым да, яшь ярымлык кызым да русча бер авыз сүз белмиләр иде. Шуның аркасында күпме шелтә сүзләре ишетергә туры килде үземә. Имеш, баланы бакчага йөртә башлаганчы, өйдә русча сөйләшергә өйрәтергә кирәк. Соң, өйдә дә, бакчада да русча сөйләшкәч, үзенең ана теленә кайчан һәм кайда өйрәнергә тиеш соң ул бала? Аллага шөкер, ана телендә генә сөйләшкән балаларым русчаны чагыштырмача тиз үзләштерделәр, хәзерге көндә ике телне дә камил беләләр.

Форсаттан файдаланып, барлык әти-әниләргә һәм әбибабайларга мөрәҗәгать итәсем килә: балаларыгыз, оныкларыгыз белән ана телендә сөйләшегез. Әле минем, шушы яшькә җитеп, татарча гына сөйләшә, русча бер сүз дә белми торган кеше күргәнем юк. Ә теле русча сөйләшеп ачылган баланың киләчәктә ана телен өйрәнүе икеле, татарча белмәгән татарларның күпме икәнен үзегез дә күреп торасыз.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: телебезне саклау, беренче чиратта, безнең үзебездән тора. Бу дөньяга татар булып туганбыз икән, чын татар булып яшик.